ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«8» декабрь 2020 ел** **№ 983**

**Арча муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен тоту тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәктәпкәчә муниципаль белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә, Арча муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм автономиясен тәэмин итү, мәктәпкәчә гомуми белем бирү хезмәтләренең сыйфатын арттыру максатыннан, Арча районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә ата-аналар түләвен тоту тәртибен расларга (кушымта).

2. Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә (Р.Д.Мөхәммәдияров) карарны ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренә эштә файдалану өчен җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Т.Мөхәмметшинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Мөхәррәмов

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитетының*
*«8» декабрь 2020 ел, № 983*
*карарына кушымта*

**Арча муниципаль районында**
**мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы**
**муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә**
**ата-аналар түләвен тоту тәртибе**

1. Оешманы гамәлгә куючы мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата - аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүне (алга таба-ата-аналар түләве) һәм аның күләмен билгели. Балаларны карау һәм тәрбияләү дигәндә балаларны тукландыру һәм хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру, аларның шәхси гигиенасын һәм көн режимын үтәвен тәэмин итү чаралары комплексы аңлашыла.

2. Ата-аналар түләгән акчаларын тоту, гамәлгә куючы тарафыннан расланган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениесенең (алга таба-Учреждение) финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы нигезендә, күрсәткечләрнең түбәндәге исемлеге буенча гамәлгә ашырыла:

2.1. Ата-аналар түләве сыйфатында алынган акчалар балалар туклануына бәйле чыгымнарны каплауга юнәлдерелә, ул учреждениедә туклану оештыруга куела торган санитария нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә тулы һәм сыйфатлы тукландыруны тәэмин итә.

2.2. Ата-аналар түләве сыйфатында алынган акчалар учреждениедә ярдәмче персоналга хезмәт хакы түләүгә бәйле чыгымнарга юнәлдерелә.

2.3. Учреждениедә балаларның тукулануына һәм ярдәмче персоналга хезмәт хакы түләүгә бәйле чыгымнарны каплаганнан соң калган акчалар түбәндәгеләргә юнәлдерелә:

- балаларны тукландыруны һәм ризык кабул итүне оештыру өчен кирәкле җиһазлар һәм савыт-саба сатып алуга;

- кер юу һәм урын-җир әйберләрен карап тоту өчен кирәкле җиһазлар сатып алуга;

- медицина кабинетына җиһазлар сатып алуга;

-азык-төлек бүлмәсе өчен җиһазлар, технологик җайланмалар һәм көнкүреш техникасы сатып алуга;

- су җылыткычлары һәм су савытлары сатып алуга;

- карау һәм тәрбияләү белән бәйле башка хезмәтләргә (үлчәү һәм медицина җиһазларын тикшерү (поверка); әзер продукцияне, суны, туфракны, комны тикшерү);

- төркем ячейкаларына җиһазлар сатып алуга (киенү-чишенү бүлмәләрендә балалар өчен кием-салым шкафлары, караватлар, урын-җир

әйберләре саклау өчен шкафлар, хуҗалык җиһазларын һәм савыт-сабаларны саклау өчен шкафлар, тәрбияләнүчеләрнең ялын оештыру өчен кирәкле башка җиһазлар);

- азык-төлек биналарында, медицина кабинетында, кер юу, бәдрәф бүлмәсендә булган көнкүреш техникасын һәм җайланмаларын ремонтлау, урнаштыру һәм карап тоту хезмәтләре күрсәтүгә, шулай ук әлеге җайланмаларга запас частьләр сатып алуга;

- тәрбияләнүчеләрнең ялын оештыру өчен кирәкле уенчыклар, уен кулланмалары, спорт җиһазлары, музыкаль җиһазлар, канцтоварлар һәм башка матди запаслар сатып алуга;

- төркемнәрне аеру принцибын исәпкә алып, балалар бакчасының уен территориясе зонасын (урамда төркемләп йөрү һәм физкультура мәйданчыклары) җиһазлауга;

- учреждениедә баланы карау һәм тәрбияләү өчен кирәкле материаль запаслар сатып алуга: юу һәм дезинфекцияләү чаралары, сабын, кер юу порошогы, бәдрәф кәгазе, тастымаллар, кәгазь сөлге һәм кулъяулыклар, урын-җир әйберләре, сөлге һәм башка йомшак җиһаз, медикаментлар, вак хуҗалык җиһазлары, тәрбияләнүчеләрнең туклануын, тәрбияләүне һәм көндезге йокысын оештыру өчен кирәкле башка товарлар һәм материаллар;

-тәрбияләнүчеләр өчен яңа ел бүләкләре сатып алуга.

3. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениесенең күчемсез мөлкәтен карап тотуга чыгымнарны баланы карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенә кертү рөхсәт ителми (төзелеш материаллары һәм буяу-лак әйберләре).